ЙОЗ МОЩЕ



МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН

Авторы *ВЛАДИМИР БАТЫР*

Художнигы *В. ИГНАТЬЕВ*

Тәрҗемәчесе *Әхмәт Исхак*

Редакторы *Х. Камалов*

Художество редакторы *Ш. Н. Мөхәммәтҗанов*

Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*

Корректоры *С. Г. Аблаезова*

Производствога бирелде 24|XI-1958 ел. Басарга кул куелды 8|I-1959 ел. Кәгазь форматы 70x92[1]|16. Учетн.-изд. 1,24 табак. Басма табак 1,0(1,17)
Заказ № А-526. Тираж 10000 экз. Бәясе 90 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1959 ел.



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1959



Йөз мәче киткән урманга,

Бергәләп филләр ауларга.








Бар да коралланганнар,


Туп һәм мылтык алганнар.

Саф-саф булып чыкканнар,

Быргылар кычкыртканнар.









Тик күрүгә ике филне,
Йөз мәче чигенгән кире.

Булган чөнки ул филләр
Бик зурлар һәм көчлеләр,
Гәүдәләре — тау чаклы,
Башлары — бозау чаклы.








Мәчеләр ташлап тупларын,
Сөнгеләрен, мылтыкларын,
Карап та тормый артка,
Качканнар төрле якка.







Бар җәнлек көлгән алардан,

Бу мактанчык аучылардан.

Көлгән жираф та, янут та,

Капкорсаклы бегемот та.

Хәтта куяннар күреп,

Үлә язганнар көлеп.








әбәп шул: бу йөз мәче
Надан булган һәммәсе:
Филләр турында алар
Берни укымаганнар.




ФИЛЛӘР
ТУРЫНДА

90 тиен.



ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ